**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 03.03.2020

КАРАР
№ ПР-37

**"Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне үткәрү турында"**

Актаныш муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү эшенең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан,

**карар бирәм:**

1. Актаныш муниципаль районы хәрби комиссариатына Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният һәм агарту эшләре бүлеге белән берлектә 2020 елның 14 апрелендә призывник көнен үткәрүне оештырырга. Хәрби хезмәткә чакырылучыларның район көнен үткәрү планын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына 2020 елның 14 апрелендә чараны үткәрү урынына армиягә чакырылучыларның һәм аларның әти-әниләренең килүен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
3. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2 нче кушымта нигезендә 2020 елның язында чакырылырга тиешле призывникларга бүләкләр алу өчен хәрби комиссариатка (Актаныш районы, муниципаль) 5810.00 сум күләмендә акча бүлеп бирүне күздә тотарга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карарына
03.03 2020 ел ПР-31
1 нче номерлы кушымта

**Хәрби хезмәткә чакырылучыларның район көнен үткәрү**
**П Л А НЫ**

| № т/б | чараларның аталышы | үткәрү вакыты | җаваплы | үткәрү урыны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Хәрби хезмәткә чакырылучыларны һәм аларның ата-аналарына хәбәр итү һәм җыю | 9: 00<br>17.04.2020 ел | Актаныш районы хәрби комиссариаты, авыл җирлекләре башлыклары | Милли- мәдәни үзәк “Яшьлек” |
| 2. | Җыелма | | | |
| | Хәрби хезмәткә чакыру һәм аның барышы белән бәйле Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе маддәләрен җиткерү буенча чакырылыш комиссиясе рәисе чыгышы; | 9: 00-9:15 | хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе рәисе | Милли-мәдәни үзәк “Яшьлек” |
| | "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында” РФ законын аңлату белән район ВК бүлеге начальнигы чыгышы; | 9:15-9:30 | хәрби комиссар Актаныш районы | Милли-мәдәни үзәк ”Яшьлек” |
| | район прокурорының “Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның җаваплылыгы " темасына чыгышы; | 9:30-9:45 | район прокуроры | Милли-мәдәни үзәк “Яшьлек" |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең чакырылыш контингентының сәламәтлеге торышы буенча өлкән табиб чыгышы; | 9: 45-10: 00 | баш табиб | Милли-мәдәни үзәк “Яшьлек" |
| | Бөек Ватан сугышында катнашучылар, сугышчы-интернационалистлар һ. б. Чыгышы; | 10: 00 – 10:15 | | Милли-мәдәни үзәк “Яшьлек” |
| | армиягә чакырылучыларның һәм аларның әти-әниләренең теләкләре | 10:15-10:30 | | Милли-мәдәни үзәк “Яшьлек” |
| | булган сорауларны тикшерү | 10: 30-10: 45 | | Милли-мәдәни үзәк “Яшьлек" |
| 3. | Үзешчәннәр концерты | 10: 45-11: 15 | мәдәният бүлеге мөдире | Милли-мәдәни үзәк “Яшьлек" |
| 4. | Тәнәфес | 11: 15-11: 30 | | |
| 5. | Бүләкләр тапшыру белән спорт ярышлары | 11: 30 дан | яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы | Балалар иҗат йорты |

Искәрмә: Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган җаваплы затлар, килешенеп, призывник көнен үткәрү планына кертелә

Актаныш муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
03.03 2020 нчы ел ПР-37

2 нче санлы кушымта

**ПРИЗЫВНИК КӨНЕН ҮТКӘРҮГӘ ЧЫГЫМНАР СМЕТАСЫ**

| № т/б | Чыгымнар исеме | Сумма |
|---|---|---|
| **1** | Приз фонды (ату, йөгерү, гер күтәрү, АКМ җыю)<br>1 урын-300 сум х 5 кеше-1.500 сум.<br>2 урын-250 сум х 5 кеше-1.250 сум.<br>3 урын-200 сум х 5 кеше-1.000 сум. | 3750 сум. |
| **2** | Грамота-10 сум х 18 кеше-180 сум. | 180 сум. |
| **3** | Блокнот һәм ручка 40 сум х 47 кеше = 1880 сум. | 1880 сум. |
| **4** | **БАРЛЫГЫ:** | **5810 сум.** |